**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2024 ел** **№ 6**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 22 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, , Татарстан урамы, 69а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2024 елның 22 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының  икенче, этабларын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, Татарстан урамы 3а нче йорт адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык бинасында,.

3. 2024 елның 22 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының  өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ташлы-Елга авылы, , Татарстан урамы, 69а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны карап тоту, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, янгын сүндерү гидрант һәм тирәнлек насосы, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту буенча башка төр эшләр;);

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Ташлы Елга авылы территориясен төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
(юлларны җәйге карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, табигый яткан грунтларда куакларны һәм вак урманнарны кисү проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Ташлы Елга авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау буенча башка төр эшләр);
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (яр буе зоналарын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы М.Ф.Зайнутдинов